| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
|---|---|---|
| **от 09.11.2015** | г. Казань | **№ 332** |

**Шундый түләү (стандартлаштырылган тариф ставкалары) зурлыгын билгеләү өчен куелган, территориаль бүлү электр челтәрләренә һәм тариф ставкаларына технологик кушкан өчен түләү куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәтләре тарифлары буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты тарафыннан бирелгән Административ регламентны раслау турында**

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 210-ФЗ Федераль законга ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Шундый түләү (стандартлаштырылган тариф ставкалары) зурлыгын билгеләү өчен куелган, территориаль бүлү электр челтәрләренә һәм тариф ставкаларына технологик кушкан өчен түләү куллануга бәйле бәхәсләрне көйләү кагыйдәләрен раслау турында»гы 2009 елның 09 гыйнварындагы карары белән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт власте башкарма органнарының дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын һәм разработка тәртибен раслау һәм Татарстан Республикамы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»гы 880нче карары белән,

әмер итәм:

1. Шундый түләү зурлыгын (стандартлаштырылган тариф ставкалары) билгеләү өчен куелган, территориаль бүлү электр челтәрләренә һәм (яисә) тариф ставкаларына технологик кушкан өчен түләү куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәтләре тарифлары буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты тарафыннан бирелгән Административ регламентка әлеге әмерне беркетүне расларга (алда – Регламент).

2. Дәүләт хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итүче рәис урынбасарына, структур бүлекчә җитәкчесенә, затка әлеге Регламентның положениеләренә нигезләнергә.

3. Информатизация бүлегенә Татарстан Республикасының «Татарстан Республиксы Рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составында тарифлар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының рәсми сайтында Регламент урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Үз көченнән чыгарылды дип танырга:

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Шундый түләүләр зурлыгын (стандартлаштырылган тарифлар ставкасы) билгеләү өчен куелган, территориаль бүлү электр челтәрләренә һәм (яисә) тариф ставкаларына технологик кушкан өчен түләү куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәтләре тарифлары буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты тарафыннан бирелгән Административ регламентны раслау турында»гы 2011 елның 14 февралендәге 32нче әмере;

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2012 елның 6 мартындагы «Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2011 елның 14 февралендәге 32нче әмере белән раслаган, шундый түләүләр зурлыгын (стандартлаштырылган тариф ставкалары) билгеләү өчен куелган, территориаль бүлү электр челтәрләренә һәм тариф ставкаларына технологик кушу өчен бәяләр куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәтләре тарифлары буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты биргән Административ регламентка үзгәрешләр кертү турында 2012 елның 6 мартындагы 53нче әмер.

5.Әлеге әмер үтәлешен контрольгә алуны Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары А.Л. Штромага йөкләргә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Килешенде:

Рәиснең беренче урынбасары А.Л. Штром

Юридик бүлек башлыгы Э.Д. Садыкова

Тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге башлыгы О.А. Шарафутдинова

Эш башкару бүлеге башлыгы А.А. Хайруллина

Мәгълүматлаштыру бүлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы М.Х. Абайдуллин

Технологик тоташтыру өчен түләүне җайга
салу һәм тикшерүдә тоту бүлеге И.Х. Шакирзянова

Боерык проектын әзерләде: технологик тоташтыру өчен түләүне җайга салу бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе К.В. Дмитриева

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты боерыгы
белән расланган
от 09.11.2015 № 332

**Татарстан Республикасы тарифлар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты тарафыннан территориаль бүлүче электр челтәрләренә техник тоташтырган өчен түләү һәм ( яисә) аның зурлыгын билгеләү өчен тәгаенләнгән тариф ставкаларын (стандартлаштырылган тариф ставкаларын) куллану белән бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү**

**АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент бүлүче территориаль электр челтәрләренә техник тоташтырган өчен түләү һәм (яисә) аның зурлыгын билгеләү өчен тәгаенләнгән тариф ставкаларын (стандартлаштырылган тариф ставкаларын) куллану белән бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү (алга таба - дәүләт хезмәтләрен күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

Дәүләт хезмәтен алучылар: челтәр оешмасы, технологик тоташтыруны башкару турында килешү төзү өчен челтәр оешмасына мөрәҗәгать итүче зат, технологик тоташтыруны башкару турында челтәр оешмасы белән килешү төзегән зат (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) күрсәтә.

1.3.1. Дәүләт комитетының урнашу урыны: Казан шәһәре., К.Маркс урамы, 66 йорт.

Дәүләт комитетының эш графигы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00 дән 18.00 сәгатькәчә, җомга 9.00 дән 16.45 сәгатькәчә, шимбә һәм якшәмбе- ял көннәре.

Җәмәгать транспортында:

10а, 22, 28, 28а, 30, 35, 54, 63, 83, 89, 91, 98 санлы автобуслар, 2, 3, 5, 7, 8 санлы троллейбуслар белән “Толстой” тукталышына кадәр барырга.

Керү шәхесне раслаучы документ белән.

1.3.2. Дәүләт комитетының технологик тоташтыру өчен түләүне җайга салу һәм контрольдә тоту бүлегенең (алга таба- Бүлек) белешмәләр алу өчен телефоннары: 221-82-45, 221-82-47.

1.3.3. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайты адресы (алга таба- Дәүләт комитетының рәсми сайты): http://kt.tatarstan.ru, Дәүләт комитетының электрон почта адресы:kt@tatar.ru.

Дәүләт комитеты структур подразделениесенең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы хезмәткәренең электрон почта адресы: Shakirzyanova.Ilvira@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүматны түбәндәгечә алырга була:

1) Дәүләт комитеты бүлмәләрендә урнашкан дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мәгълүмати стендлары аша. Мәгълүмати стендлар 1.3.1.-1.3.2., 2.1., 2.3.-2.5., 2.8., 2.10., 2.11, 5.1. пунктларында күрсәтелгән мәгълүматлар белән баетылырга тиеш.

2) «Интернет» челтәре аша:

- Дәүләт комитетының рәсми сайтында: (http://kt.tatarstan.ru);

- Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләре порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

- дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләре(функцияләре) Бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

- Дәүләт комитетына телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефоннан);

- Дәүләт комитетына язмача мөрәҗәгать иткәндә (почта аша яисә Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет – кабул итү төренең электрон рәвешен куллану аша).

1.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Дәүләт комитеты хезмәткәрләре тарафыннан рәсми сайтта һәм Дәүләт комитеты бүлмәләрендә урнашкан мәгълүмати стендларында урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге законнарга таянып башкарыла:

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35- ФЗ санлы Федераль законга (алга таба- 35- ФЗ санлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 31.03.2003, №13, 1177 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законга (алга таба –210-ФЗ санлы Федераль закон) ( Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010 ел, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан 2004 елның 27 декабрендәге 861 санлы карары (алга таба- 861 санлы карар) белән расланган электр энергиясен кулланучыларның, электр энергиясен җитештерүче объектларның, шулай ук челтәр оешмаларына һәм башка затларга, шулай ук электр челтәрләренә караган электр челтәрләре объектларының энергия кабул итеп алучы җайланмаларын технологик яктан тоташтыру Кагыйдәләре (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 27.12.2004, №52 (2 бүлек), 5525 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан 2009 елның 9 гыйнварындагы 14 санлы карары (алга таба- 14 санлы карар) белән расланган техник

тоташтыру өчен түләүләрне һәм бәяләрне( тарифларны) дәүләти җайга салу органнары тарафыннан аның күләмен билгеләү өчен тәгаенләнгән тариф ставкаларын (стандартлаштырылган тариф ставкаларын) билгеләүгә һәм куллануга бәйле бәхәсләрне җайга салу Кагыйдәләре (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 19.01.2009, №3, 414 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге «Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты мәсьәләләре» 468 санлы карары (алга таба- 468 санлы карар) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, 04.08.2010 № 29, 1195 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып; 12.2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан күрсәтелүче дәүләт хезмәтләренә административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 880 санлы карары (алга таба - ТР Министрлар Кабинетының 880 санлы карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, 08.12.2010 № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата - Дәүләт комитеты тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән мәгълүматларның (дәүләт хезмәте нәтиҗәсе) әлеге мәгълүматлар нигезендә язылган документның дөрес булмавына китергән хата (ялгыш язылу, ялгыш басылу, грамматик яки арифметик хата);

күп функцияле үзәкләрнең ераклаштырылган эш урыннарында дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү- муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә гариза бирүчеләрне консультацияләү, документлар кабул итү һәм тапшыру тәрәзәсе.

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза)- 210-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсе 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос. Гаризаның тәкъдим ителгән формасы әлеге Регламентның 1нче Кушымтасында бирелә.

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартлары

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне билгеләүче норматив акт яисә таләп |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Территориаль электр челтәрләренә техник тоташтырган өчен түләү һәм ( яисә) аның зурлыгын билгеләү өчен тәгаенләнгән тариф ставкаларын (стандартлаштырылган тариф ставкаларын) куллану белән бәйле бәхәсләрне карау | 35-ФЗ санлы Федераль закон ; 14 санлы карар |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты | 468 санлы карар |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулысы белән яисә өлешчә) канәгатьләндерү турында яисә аларны канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар | 14 санлы карарның 17 пункты |
| 2.4.Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору, әгәр дә туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган булса. | Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты 30 көн.<br>Өстәмә мәгълүматлар алу,бәхәсне тикшерүгә башка затларны җәлеп итү һәм (яисә) экспертиза үткәрү вакыты җайга салу органы тарафыннан өстәмә мәгълүматлар алу яисә бәхәсне тикшерүгә башка затларны җәлеп итү һәм (яисә) экспертиза үткәрү зарурлыгы турында карар кабул ителгән көннән алып 60 көннән артып китә алмый.<br>Шуның белән бергә күрсәтелгән вакытны кабат туктатып тору рөхсәт ителми.<br>Бәхәс, аны карауны туктатып тору өчен нигез булып торган сәбәпне юкка чыгаргач, яңадан тикшерелә башлый. | 14 санлы карар |
| 2.5.Дәүләт хезмәтләрен күр- | Гариза (1 нче кушымта). | 14 санлы карарның 8,9,10 |

| | | |
|---|---|---|
| сәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган кирәкле документ-ларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе | Үткәреп җибәрелгән срокны яңадан кайтару турында үтенеч (гаризаны билгеләнгән вакытыннан соң тапшырган очракта).<br>Гариза бирүче үз таләпләрен нигезләгән хәл-сәбәпләрне раслаучы (гариза бирүче фикере буенча) документлар (төп нөсхәләре һәм күчермәләре).<br>Гариза һәм документлар ике экземплярда тапшырыла.<br>Әгәр дә бәхәскә документның бер өлешенең генә катнашы бар икән, документтан расланган өземтә тапшырыла.<br>Гариза бирүче тарафыннан бирелгән барлык документлар, әгәр дә аларның битләре бер биттән артса, номерланган, тегелгән һәм соңгы биттә мөһере( булганда) сугылган һәм гариза бирүченең яисә аның вәкаләтле вәкиле имзасы белән расланган булырга тиеш.<br>Гаризаны шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми порталының Интернет – кабул итү» төре аша электрон рәвештә юнәлтергә мөмкин.<br>Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләр юк. | пунктлары |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагын-дагы, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу | 1. Юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан (Татарстан Республикасы Федераль салым хезмәте идарәсендә) өземтә.<br>2.Шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан (Татарстан Республикасы Федераль салым хезмәте идарәсендә) өземтә | 14 санлы карарның 9 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе | | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма орган тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Юк. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү-не туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Гариза бирүче зат үз хокукларының бозылуы хакында<br>белгән яисә белергә тиеш булган көннән алып 90 көн үткәч нигезле сәбәпләрсез гариза бирү.<br>2. Тәкъдим ителгән документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәү.<br>3. Гариза бирүче тарафыннан тәкъдим ителгән документларда нинди дә булса мәгълүматларның булмавы яисә ышанычсыз мәгълүматларга ия булуы.<br>4. Тапшырылган документларда төзәтүләр булу.<br>5. Документлар тапшырырга вәкаләте булмаган яисә гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклау хокукынраслаучы документ- | 14 санлы карар, 14 санлы карарның 13 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | лары (ышанычнамәсе) булмаган зат тарафыннан документлар тапшыру.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге очракларда туктатылып торырга мөмкин:<br>өстәмә мәгълүматлар алу яисә бәхәсне тикшерүгә башка затларны җәлеп итү;<br>экспертиза үткәрү. | |
| 2.10.Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы хезмәт күрсәтүләргә түләүләрнең тәртибе, күләме һәм түләү алу нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Тиешле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү зарурлыгы таләп ителми<br>Дәүләт хезмәте алучының (гариза бирүченең) кабул итүне (хезмәт | 14 санлы карар |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте алучының (гариза бирүченең) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Чиратта көтүнең күрсәтелгән вакытына төшке аш вакыты һәм эштән соңгы вакыт кертелми. | 2012 елның 7 маендагы 601 санлы РФ Президенты Указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап мөрәҗәгать | Гариза кергән көн эчендә | 14 санлы карар |

| | | |
|---|---|---|
| итүченең запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон формада | | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләр өчен көтеп тору һәм аларны кабул итү урынына, шундый хезмәт күрсәтүләр тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте түбәндәге рәвештә җиһазландырылган бүлмәләрдә күрсәтелә:<br>һаваны җилләтү системасы;<br>янгынга каршы һәм янгын сүндерү системасы;<br>документлар рәсмиләштерү өчен җиһазлар;<br>мәгълүмати стендлар.<br>Мәгълүматлар куелган эленмә такталары, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы мәгълүматлар Дәүләт комитетының төп керү урынында һәм гражданнар мөрәҗәгать итү бүлегенә керү урынында эленгән мәгълүмати стендларга урнаштырылган. | |
| 2.15.Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәтен алганда гариза бирүченең вазыйфаи зат белән үзара бәйләнеше саны һәм аның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен күп функцияләр башкаручы үзәктә, күп функцияләр башкаручы үзәкнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре:<br>1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү срогы үтәлү;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алу срогы үтәлү;<br>3) дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмау (прецедентлар, шикаятьләр санының Дәүләт комитетының хезмәт күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гомуми санына чагыштырмасы).<br>4) гариза бирүченең Дәүләт комитеты белгечләре белән үзара бәйләнеш саны ике тапкырдан артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>5) гариза бирүче белән бәйләнеш вакыты озынлыгы – 15 минуттан да артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып тора: | |

| | | |
|---|---|---|
| турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып мәгълүмат алу мөмкинлеге | 1) документларны кабул итү һәм тапшыру бинасының җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашуы;<br>2) кирәкле санда белгечләрнең булуы, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итеп алу өчен кирәкле санда бүлмәләрнең булуы;<br>3) мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендәге, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталындагы мәгълүмат ресурсларында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүматның булуы.<br>Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә, күп функцияләр башкаручы үзәкнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыннарында күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып мәгълүмат алу мөмкинлеге юк. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Гаризаны электрон рәвештә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының интернет аша кабул итүе аркылы бирелә (алга таба – Интернет аша кабул итү).<br>Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi.tatar.ru), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы аша (http://www.gosuslugi.ru), электрон документ формасында гариза бирү мөмкинлеген файдаланган очракта, дәүләт хезмәте нәтиҗәсе электрон формада бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре , шулай ук күп функцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче күп функцияле үзәкләрнең ераклаштырылган эш урыннарында административ процедураларның үтәлү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза язу өлешендә;

2) теркәлгән документлар белән гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар төзү һәм җибәрү;

4) гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулысы белән яисә өлешчә) канәгатьләндерү турында боерыкны әзерләү һәм раслау, яисә яисә аларны канәгатьләндерүдән баш тарту (баш тарту турында хәбәр бирү );

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү

3.2.1. Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Дәүләт комитетына шәхсән, телефоннан һәм (яки) электрон почта һәм (яисә) Татарстан Республикасының рәсми порталының Интернет – кабул итү төрен куллану аша мөрәҗәгать итә.

Дәүләт комитетының технологик тоташтыру өчен түләүне җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге (алга таба- Бүлек) белгече шәхсән, телефоннан, электрон почта һәм ( яисә) хат аша, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләре порталында гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән гаризаның һәм тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан һәм дәүләт хезмәте алуга карата башка мәсьәләләр буенча консультация бирә һәм шулай ук , кирәк булганда, гаризаны төзүдә булышлык күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: тапшырыла торган гаризаның һәм документларның составы, формасы ягыннан һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләр, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән үзе, ышанычлы зат аша, почта, Татарстан Республикасының рәсми порталының Интернет – кабул итү төрен куллану аша

территориаль электр челтәрләренә техник тоташтырган өчен түләү һәм (яисә) аның зурлыгын билгеләү өчен тәгаенләнгән тариф ставкаларын (стандартлаштырылган тариф ставкаларын) куллану белән бәйле бәхәсләрне карау турында гаризаны Дәүләт комитетының эш кәгазьләрен башкару бүлегенә (алга таба- Эш кәгазьләрен башкару бүлеге) юнәлтә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы аша бирелә ала.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза бирүче үз хокукларының бозылуы хакында белгән яисә белергә тиеш булган көннән алып 90 көн эчендә башкарылалар.

Процедура нәтиҗәсе: гариза һәм документлар.

3.3.2. Эш кәгазьләрен башкару бүлеге белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны һәм документларны кабул итү;

документларны беренчел эшкәртү һәм гаризаны электрон формада “Электрон Хөкүмәт” Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында (алга таба – электрон документ әйләнеше) теркәү номерын биреп һәм кабул итү көнен күрсәтеп, теркәү;

гариза бирүчегә документлар кабул ителгән көне күрсәтелгән, керү номеры куелган, дәүләт хезмәте күрсәтү көне һәм вакыты билгеләнгән гаризаның күчермәсен тапшыру яки почта аша яки электрон почта (теләге булса) аша җибәрү;

гаризаны электрон формада электрон документ әйләнеше аша Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты рәисенә (рәис урынбасарына) (алга таба – рәис (рәис урынбасары) юллау.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм рәискә (рәис урынбасарына) юлланган гариза.

3.3.3. Рәис (рәис урынбасары) гаризаны караганнан соң, аны карау өчен рәис урынбасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәис урынбасарына юлланган гариза.

3.3.4. Рәис урынбасары гаризаны караганнан соң, карау өчен аны Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек мөдиренә карау өчен юлланган гариза.

3.3.5. Бүлек җитәкчесе гаризаны һәм документларны карый, җаваплы башкаручыны (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм гаризаның 14 санлы

карарда билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү максатында карау өчен гаризаны аңа тапшыра.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедура тәмамланган мизгелдән алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла,

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә башкару өчен юлланган гариза һәм документлар.

3.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар төзү һәм юнәлтү

3.4.1. Бүлек белгече ведомоствоара электрон документлар әйләнеше системасында электрон формада Татарстан Республикасы Федераль салым хезмәте идарәсенә юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан яисә шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүмат бирүне сорап запрос юнәлтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган мизгелдән алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла, әмма алдагы процедура тәмамланган мизгелдән алты эш көненнән соңга калмыйча башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирүне сорап ясалган запрослар.

3.5. Гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулысы белән яисә өлешчә) канәгатьләндерү турында боерыкны әзерләү һәм раслау, яисә яисә аларны канәгатьләндерүдән баш тарту (баш тарту турында хәбәр бирү )

3.5.1. Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

документларны норматив- хокукый нигезен һәм бәхәсләрне карап тикшерү буенча гаризада билгеләнгән проблема буенча барлыкка килгән хокук кулланышы практикасын исәпкә алып өйрәнү һәм карап тикшерү;

гаризаны карау өчен кабул итү яисә гаризаны караудан баш тарту турындагы боерык проектын әзерләү;

карарны килештерү өчен Бүлек башлыгына юнәлтү.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза кергән мизгелдән алып ун эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек башлыгына юнәлтелгән гаризаны карау өчен кабул итү яисә гаризаны караудан баш тарту турындагы карар проекты.

3.5.2. Бүлек башлыгы карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм Дәүләт комитеты рәисенә (рәис урынбасарына) килештерү өчен юнәлтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура 3.5.1 пунктында каралган процедура тәмамланган мизгелдән алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла яисә әлеге Регламентның 3.5.6. пунктында каралган өстәмә мәгълүматлар алу зарурлыгы яисә карап тикшерүгә башка затларны җәлеп итү яисә өстәмә экспертиза үткәрү очраклары килеп туганда башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Дәүләт комитеты рәисенә килештерү өчен юнәлтелгән гариза проекты .

3.5.3. Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) карар проектын карап тикшергәч, гаризаны карау өчен кабул итү яисә гаризаны караудан баш тарту турындагы карар кабул итә һәм әлеге карарны гариза бирүчегә юллау өчен Эш кәгазьләрен башкару бүлегенә юнәлтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган мизгелдән алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла,

Процедуралар нәтиҗәсе: гаризаны карау өчен кабул итү яисә гаризаны караудан баш тарту турындагы карар (баш тарту турында хат юллау).

3.5.4. Эш кәгазьләрен башкару бүлеге белгече кабул ителгән карарны терки һәм аның күчермәсен гариза бирүчегә юнәлтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган мизгелдән алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юнәлтелгән карар күчермәсе.

3.5.5. Гаризаны карап тикшерү өчен карар кабул ителгән очракта Дәүләт комитеты гариза бирүчене, респондентны (алга таба - якларны) һәм, кирәк булганда, башка кызыксынган затларны чакырып киңәшмә үткәрә.

3.5.5.1. Бүлек белгече, гаризаны карап тикшерү буенча кабул ителгән карарны алгач, түбәндәгеләрне башкара:

бәхәсне карап тикшерү буенча киңәшмәне үткәрү көне, вакыты һәм урыны турында якларга телефон элемтәсе аша, яисә якларның адресларына факсограмма юнәлтеп, хәбәр итү;

Дәүләт комитетының юридик бүлегенә киңәшмәдә катнашу өчен чакыру һәм әлеге киңәшмә кысаларында каралачак бәхәс буенча материаллар юнәлтү;

киңәшмәне үткәрү өчен җаваплы булган белгечкә гариза бирүченең гаризасын, документларын, барлыкка килгән бәхәс буенча бәяләмәләрне, карап тикшерү турындага гаризаны кабул итү турындагы карарны юнәлтү;

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган мизгелдән алып ике көн эчендә, бәхәсне карап тикшерү көненә кадәр 5 көн кала гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: бәхәсне карап тикшерү буенча киңәшмәне үткәрү көне турында якларга һәм юридик бүлек белгечләренә хәбәр итү; киңәшмәне үткәрү өчен җаваплы булган белгечкә юнәлтелгән материаллар.

3.5.5.2. Киңәшмәне үткәрү өчен җаваплы булган белгеч киңәшмәдә катнашучы затларны теркәүне һәм аларның исемлеген рәискә (рәис урынбасарына) тапшыруны тәэмин итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура киңәшмә башланыр алдыннан гамәлгә ашырыла,

Процедуралар нәтиҗәсе: рәислек итүчегә тапшырылган киңәшмәдә катнашучы затлар исемлеге.

3.5.5.3. Рәис (рәис урынбасары) нәтиҗәләре буенча түбәндә күрсәтелгән карарларның берсе кабул ителгән киңәшмә үткәрә:

- гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулысы белән яисә өлешчә) канәгатьләндерү турында рәиснең (рәис урынбасарының) тиешле боерыгы проектын әзерләү зарурлыгы хакында;

- гаризада күрсәтелгән таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында рәиснең (рәис урынбасарының) тиешле боерыгы проектын әзерләү зарурлыгы хакында;

- әлеге Регламентның 3.5.6- 3.5.7 пунктлары нигезендә, өстәмә мәгълүматлар алу яисә бәхәсне тикшерүгә башка затларны җәлеп итү һәм (яисә) экспертиза үткәрү, кирәк булганда, документларны карау вакытын озынайту зарурлыгы хакында.

Процедуралар нәтиҗәсе: гаризада күрсәтелгән таләпләрне канәгатьләндерү яисә канәгатьләндерүдән баш тарту турында рәис (рәис урынбасары) тарафыннан кабул ителгән карар яисә өстәмә мәгълүматлар алу яисә бәхәсне тикшерүгә башка затларны җәлеп итү һәм (яисә) тәкъдим ителгән документларга өстәмә экспертиза үткәрүне билгеләү, һәм документларны карау вакытын озынайту зарурлыгы турында кабул ителгән карар.

3.5.6. Бүлек белгече:

гариза бирүче адресына өстәмә мәгълүматлар алу яисә бәхәсне тикшерүгә башка затларны җәлеп итү һәм (яисә) документларга өстәмә экспертиза үткәрү һәм документларны карау вакытын озынайту зарурлыгы турында хәбәр әзерли.

хәбәрне Бүлек башлыгына һәм Рәискә (рәис урынбасарына) килештерүгә юнәлтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар өстәмә мәгълүматлар алу яисә бәхәсне тикшерүгә башка затларны җәлеп итү һәм (яисә) тәкъдим ителгән документларга өстәмә экспертиза үткәрүне билгеләү, һәм документларны карау вакытын озынайту зарурлыгы турында кабул ителгән карар кабул ителгән мизгелдән бер көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юнәлтелгән хәбәр.

3.5.7. Бүлек белгече өстәмә мәгълүматлар алу яисә бәхәсне тикшерүгә башка затларны җәлеп итү (яисә) тәкъдим ителгән документларга өстәмә экспертиза үткәрүне һәм гаризаны карау вакытын озынайту зарурлыгы турында кабул ителгән карар нигезендә түбәндәгеләрне башкара:

өстәмә мәгълүматлар алу яисә бәхәсне тикшерүгә башка затларны җәлеп итү;

мәсьәләне икътисадый, хокукый яисә технологик яктан анализлау өчен экспертиза үткәрү;

бәяләмә проектын хәзерләү;

бәяләмә проектын Бүлек башлыгына килештерүгә юнәлтү;

әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар өстәмә мәгълүматлар алу яисә бәхәсне тикшерүгә башка затларны җәлеп итү (яисә) тәкъдим ителгән документларга өстәмә экспертиза үткәрүне һәм гаризаны карау вакытын озынайту зарурлыгы турында карар кабул ителгән көннән 5 көннән дә соңга калмыйча башкарыла:

Процедуралар нәтиҗәсе: бәяләмә проекты.

Әлеге пункт билгеләгән процедура киңәшмә үткәрелгән көндә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулаем яисә өлешчә) канәгатьләндерү турында яисә таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында кабул ителгән карар.

3.5.8. Киңәшмәне үткәрү өчен җаваплы булган белгеч киңәшмә нәтиҗәләре буенча:

киңәшмәдә каралган мәсьәләләрнең кыскача эчтәлеген үз эченә алган бәхәсне карап тикшерү беркетмәсен, кабул ителгән карарлар турында мәгълүмат әзерли;

гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулаем яисә өлешчә) канәгатьләндерү турында яисә таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында боерык проектын әзерли;.

беркетмәне һәм боерык проектын рәискә ( рәис урынбасарына) раслауга юнәлтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура киңәшмә үткәрелгән көннән алып ике көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: рәискә (рәис урынбасарына) юнәлтелгән киңәшмәнең рәсмиләштерелгән беркетмәсе, боерык проекты.

3.5.9. Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) киңәшмә беркетмәсенә имзасын куя һәм гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулаем яисә өлешчә) канәгатьләндерү турында яисә таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында боерыкны раслый һәм Бүлеккә юнәлтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган мизгелдән алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган беркетмә, расланган боерык.

3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру

3.6.1. Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

боерык күчермәләрен якларга юнәлтү;

боерыкны Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыру өчен Дәүләт комитетының информатизация бүлегенә юнәлтү.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура боерык расланган көннән алып ике көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: якларга һәм Дәүләт комитетының информатизация бүлегенә юнәлтелгән гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулаем яисә өлешчә) канәгатьләндерү турында яисә таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында кабул ителгән боерык күчермәләре.

3.6.2. Бүлек белгече бәхәсне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча документларны Дәүләт комитеты архивына юнәлтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган мизгелдән өч көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: архивка тапшырылган документлар.

3.7. Электрон формада кергән гаризаны карау

3.7.1. Электрон формада керүче гариза әлеге Регламентның 3.3.2-3.3.5 пунктларында каралган тәртиптә теркәлә.

Дәүләт хезмәте күп функцияле үзәкләр, күп функцияле үзәкләрнең ераклаштырылган эш урыннары аша күрсәтелми.

3.8. Техник хаталарны(ялгыш язуларны, ялгыш басуларны, грамматик һәм арифметик хаталарны) төзәтү

3.8.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хаталар (ялгыш язулар, ялгыш басулар, грамматик  һәм арифметик хаталар) булу ачыкланса, гариза бирүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хаталарны (ялгыш язуларны, ялгыш басуларны, грамматик һәм арифметик хаталарны) төзәтү турында гаризаны (3 кушымта);

гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы (ялгыш язулар, ялгыш басулар, грамматик һәм арифметик хаталар) документны;

техник хаталар (ялгыш язулар, ялгыш басулар, грамматик һәм арифметик хаталар) булуны таныклаучы юридик көчкә ия булган документларны;

дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документтагы мәгълүматларда техник хаталарны (ялгыш язуларны, ялгыш басуларны, грамматик һәм арифметик хаталарны) төзәтү турында гариза гариза бирүче ( аның вәкаләтле ваәкиле) тарафыннан шәхсән тапшырыла, яисә почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып) яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләренең бердәм порталы аша юнәлтелә.

3.8.2. Бүлек белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен теркәү кенәгәсенә терки.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.8.3. Бүлек башлыгы документларны карый һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максатында әлеге Регламентның 3.5. пунктында каралган процедураларны башкара һәм гариза бирүчедән (аның вәкаләтле вәкиленнән) кул куйдыртып, аңа шәхсән төзәтелгән документны тапшыра, ә техник хата (ялгыш язулар, ялгыш басулар, грамматик һәм арифметик хата) ачыкланган документның төп нөсхәсен гариза бирүчедән (аның вәкаләтле вәкиленнән) кире ала яисә гариза бирүченең адресы буенча почта аша(электрон почта аша) техник хата (ялгыш язулар, ялгыш басулар, грамматик һәм  арифметик хата) ачыкланган документны алу мөмкинлеге турында хат юнәлтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура, техник хата (ялгыш язулар, ялгыш басулар, грамматик һәм арифметик хаталар) ачыкланган өч көн эчендә яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата (ялгыш язулар, ялгыш басулар, грамматик һәм арифметик хата) турында гариза кабул иткәч, башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (юнәлтелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт комитеты вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт вазифаларын үтәлешен контрольдә тота, вазыйфаи затлар тарафыннан үз хезмәт вазифаларын тиешле рәвештә үтәмәүләре очракларын исәпкә ала, тиешле хезмәт тикшерүләрен үткәрә һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге вазыйфаи затларга карата чаралар күрә.

4.2. Әлеге Регламент үтәлешенә контрольлек итү Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан башкарыла.

4.3. Әлеге Регламент нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү үтәлеше буенча срокларны, гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүне, Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының карарлар кабул итүен агымдагы контрольдә тотуны Дәүләт комитеты рәисе урынбасары һәм Дәүләт комитетының үз компетенциясенә дәүләт хезмәте күрсәтү үтәлеше кергән Бүлек башлыгы гамәлгә ашыра.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатлы үтәлешен тикшерү планлы һәм планнан тыш була ала.

Планлы тикшерүләр Дәүләт комитетының расланган еллык эш планы нигезендә үткәрелә.

Планнан тыш тикшерүләр күрсәтелә торган дәүләт хезмәте үтәлеше барышында вазыйфаи затлар тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауларына) гражданнарның шикаятьләре нигезендә оештырылалар һәм үткәреләләр.

Тикшерүләр кызыксынган затларның хокукларын бозуны ачыклауны һәм бетерүне, Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр буенча карар кабул итү һәм җавап әзерләү максатында үткәреләләр.

Дәүләт хезмәт күрсәтү үтәлешенә таләпләр билгеләүче әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм норматив-хокукый актларын Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан тикшерү ешлыгы Дәүләт комитетының расланган агымдагы еллык эш планы нигезендә билгеләнә.

4.5. Гариза бирүчеләр ягыннан, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан Регламентның үтәлешен контрольдә тоту Дәүләт комитетына мөрәҗәгать юнәлтү юлы белән, шулай ук Регламент үтәлеше барышында дәүләт хакимияте органнарына кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү юлы белән башкарыла.

4.6. Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары үз хезмәт вазифаларын тиешенчә үтәмәгән, тикшерүләр барышында хокукка каршы гамәлләр кылган (гамәлләр кылмаган)очракларда Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

Гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында Дәүләт комитеты шул чараларны кабул иткән көннән алып ун көн эчендә хокуклары һәм яисә законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә

язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

## 5. Дәүләт комитетының, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар Дәүләт комитетының, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең кылган (кылмаган) гамәлләренә карата Дәүләт комитетында судка кадәр тәртиптә шикаять белдерүгә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле рәис кабул иткән карарларга, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата белдерелгән шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Дәүләт комитеты, аның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.2. Дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан шикаять почта буенча, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән, Интернет – кабул итү төреннән, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып, күпфункцияле үзәк аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә алынырга мөмкин.

5.3. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән Дәүләт комитеты атамасы, аның  вазыйфаи затының яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең исеме;

гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар - физик затның яисә яисә атамасы, юридик зат булып торган гариза бирүченең урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы.

Дәүләт комитеты, аның  вазыйфаи затының яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүматлар;

Гариза бирүченең Дәүләт комитеты, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре.

5.4. Дәүләт хезмәтен алучы шикаятьне(претензияне) дәлилләү һәм карау өчен зарури булган мәгълүмат һәм документлар алырга хокуклы.

5.5. Дәүләт комитетына кергән шикаять шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләте булган вазыйфаи зат тарафыннан шикаять теркәлгән көннән алып 15 эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш. Дәүләт комитеты, аның вазыйфаи заты тарафыннан гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуга карата шикаять белдерелгәндә – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәл- сәбәпләрне раслаучы документлар күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.7. Шикаятькә гариза бирүче шәхсән яисә аның вәкаләтле заты кул куя.

5.8. Рәис (ул үзе булмаганда- аның вәкаләтле заты) шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны юкка чыгару , дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителү көненнән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон рәвештә, шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы яисә җинаять билгеләре ачылган очракта, шикаятьне карауга вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Түләү зурлыгын (стандартлаштырылган тариф ставкалары) билгеләү өчен территориаль бүленеш электр челтәренә һәм (яисә) тариф ставкаларына технологик кушу өчен түләү куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәтләре тарифлары буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитетына бирелгән административ регламентка 1нче кушымта

Тәкъдим ителгән форма

**БӘХӘСНЕ КАРАУ ТУРЫНДА ГАРИЗА**

Кемнән

________________________________________________________________________

(гариза бирүченең исеме)

________________________________________________________________________

(юридик затның эш урыны/физик затның яшәү урыны)

Тарифлар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Комитетыннан сорыйм______________________________________________________________________

________,

( гариза кемгә бирелә, шуның исеме, яшәү яисә эш урыны)

Респондентның килешмәве сәбәпле туган бәхәсне канәгатьләндерүне таләп итү турында_____________________________________________________________________

_________

________________________________________________________________________

(Россия Федерациясенең хокукый норматив актларына таянып, бәхәс китереп чыгарган гамәлләрне, карарларны күрсәтергә)

Бәхәснең асылы:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(бәхәснең асылын җентекле аңлату,ул ни өчен һәм кайчан килеп чыккан, аны җайлау өчен нинди дә булса гамәлләр кылынганмы)

Гариза бирүченең карашын нигезләү:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

_____________

(гариза бирүченең респондентка Россия Федерациясе норматив хокукый актларына таянып биргән таләпләре, ә таләпләр берничә респондентка булганда – аларның һәрберсенәз куелган таләпләр; гаризада күрсәтелгән таләпләр өчен нигез булган шартлар)

Бәхәсне карау өчен кирәкле башка белешмәләр:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

**Кушымта**:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(беркетелгән документлар исемлеге һәм аларның һәрберсендәге битләр саны)


Имза


______________________ ______________________________________

(мөһер сугу урыны) (имзаны расшифровкалау)

"_____" ___________________ 20 __ел.

Түләү күләмен (стандартлаштырылган тариф ставкалары) билгеләү өчен территориаль бүленеш электр челтәренә һәм (яисә) тариф ставкаларына технологик кушу өчен түләү куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәтләре тарифлары буенча  Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты бирелгән административ регламентка 2нче кушымта






Шундый түләү зурлыгын (стандартлаштырылган тариф ставкаларын) билгеләү өчен куелган, территориаль бүленеш электр челтәренә һәм (яисә) тариф ставкаларына технологик кушу түләүләрен куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү рәсеме - блок-схемасы

Шундый түләү зурлыгын (стандартлаштырылган тариф ставкаларын) куелган, территориаль бүленеш электр челтәренә һәм (яисә) тариф ставкаларына технологик түләүләрне кулланууга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәтләре тарифлары буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитетына бирелгән административ регламентка 3нче кушымта

Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты рәисенә

______________________________

Кемнән:___________________________

Тәкъдим ителгән форма

**Гариза**
**Техник хатаны төзәтү турында**
(ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яисә арифметик хаталар)

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яисә арифметик хата) турында хәбәр итәм ____________________________________________________________________

(хезмәт исеме)

Язылган: __________________________________________________________ ____________________________________________________________________

Дөрес белешмәләр: ______________________________________________ ____________________________________________________________________

техник хаталарны (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик һәм арифметик хата) төзәтүне сорыйм.

Түбәндәге документларны беркетәм:

1.

2.

3.

Техник хатаны ( ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик һәм арифметик хата) төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта шушы карарны җибәрүне сорыйм:

E-mail адресына электрон документ җибәрү юлы белән:______;

әлеге адрес буенча почта аша:_____________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системага салу, туплау. саклау, ачыклау (яңарту, үзгәртү) куллану, тарату (шул исәптән күчерү), акчага

әйләндерү, яптыру, шәхси мәгълүматларны юкка чыгару, шулай ук дәүләт хезмәтләре күрсәтү кысасында башка гамәлләрне юкка чыгару) бәйле, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган нигезендә кабул ителгән карарларны кертеп, мәгълүматларны автоматлаштырылган режимда карауга үземнең ризалыкны бирәм.

Гаризага минем шәхескә кагылышлы һәм мине күрсәтүче зат турындагы мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага беркетелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә яраша, гариза биргәндә бу документлар дөрес һәм мәгълүматлары чынбарлыкка туры килә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелү сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда телефон аша катнашуга үземнең ризалыкны бирәм:____________________

_____________ ________________(___________________)
(дата) (имза) (Ф.И.О.)

Шундый түләү зурлыгын билгеләү өчен (стандартлаштырылган тариф ставкалары), территориаль бүленеш электр челтәрләренә һәм (яисә) тариф ставкаларына технологик кушу өчен түләү куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча Татарстан Республикасының тарифлар буенча комитетына бирелгән административ регламентка кушымта (белешмә)

Шундый түләү (стандартлаштырылган тариф ставкалары) зурлыгын билгеләү өчен расланган, территориаль бүлү электр челтәрләренә һәм тариф ставкаларына технологик кушу өчен түләү куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәтләре күрсәткән өчен җаваплы вазифадагы затлар һәм органнар реквизитлары

| Адрес | Вазифасы, Ф.И.О. | Телефон | Кабул итү көннәре һәм сәгатьләре |
|---|---|---|---|
| 420015, Казан ш., К.Маркс ур., 66нчы йорт. | Рәис | (843) 221-82-18<br>(843) 221-82-01 | сишәмбе 14.00 сәгатьтән |
| 420015, Казан ш., К.Маркс ур., 66нчы йорт | Рәиснең беренче урынбасары | (843) 221-82-05 | сишәмбе 14.00 сәгатьтән |
| 420015, Казан ш., К.Маркс ур.,66нчы йорт | Технологик кушкан өчен түләүне көйләү һәм контрольдә тоту бүлеге җитәкчесе | (843) 221-82-45 | Дүшәмбе - пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр<br>җомга – 9:00дән 16:45 сәгатькә кадәр |